*УДК 908*

# Тәтеш төбәгенең нумизматик һәм эпиграфик истәлекләре

***Э.К. Сәлахова***
*ТР ФА Ш.Мәрҗәни исем. Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*

Хәзерге Тәтеш, Апас, Кама Тамагы һәм Буа районнарының бер өлешен үз эченә алган Тәтеш өязе – Идел буеның мөһим регионнарының берсе. Хезмәттә әлеге территориядә барлыкка килгән тарихи истәлекләр карала. Автор өйрәнүдә территориаль чикләрне билгеләү өчен «Тәтеш төбәге» дигән термин куллана. Бу җир – Идел буе Болгар дәүләтенең бер өлеше булган, ул шулай ук Җүчи Олысы вакытында да төрки-татарлар дәүләтенең мөһим бер үзәге булып калган. Кызганычка каршы, озак вакыт төрки-татарларның тарихи истәлекләрен өйрәнү хәзерге Болгар шәһәре һәм аның тирәлеге белән генә чикләнелде, ә дәүләтнең Идел елгасының уң ягында урнашкан өлеше хаксыз рәвештә күләгәдә кала килде.

Нумизматик материаллар һәм эпиграфик истәлекләр аша Тәтеш төбәгенең күпкырлы тарихын тирәнрәк һәм киңрәк өйрәнү, шулай ук аның Идел буе Болгар дәүләте һәм Җүчи Олысы тарихында әһәмиятен күрсәтү максаты куела. Әшне бу юнәлештә алып баруның актуальлегендә шик юк, чөнки тарихи чыганакларны комплекслы өйрәнү регион тарихы өчен генә түгел, ә, татар тарихында аз өйрәнелгән сәхифәләрне тулыландыруга да мөмкинлек бирә.

Мәкаләдә төп игътибар нумизматик материалларны карауга юнәлдерелгән. Тәтеш, Апас районы җирлегендә тарихи яктан мөһим булган тәңкә хәзинәләре табылган, фәндә алар «Каратун хәзинәсе» һәм «Әтрәч хәзинәсе» дип исемләнгән. Шулай ук Тәтеш төбәгенең башка авылларында да көмеш тәңкәләр очрый. Тикшерүчеләр тарафыннан Идел буе Болгар дәүләтенең тәңкә сугу урыны болгар шәһәре Шонгат (хәзерге Тәтеш районы җирләре) янында булган. Мәкаләнең икенче өлешендә элекке Тәтеш өязе җирләрендә Идел буе Болгар һәм Җүчи Олысы чорларына караган эпиграфик истәлекләр комплексы билгеләнә, шулай ук татарларның бабаларың борынгы зиратлары булган урыннар күрсәтелә.

*Ачкыч сүзләр*: нумизматика, эпиграфик истәлекләр, Тәтеш төбәге тарихы, татар халкы тарихы, Идел буе Болгар дәүләте тарихы.

Хәзерге Тәтеш, Кама Тамагы, Апас һәм Буа районнарының бер өлешен үз эченә алган Казан губернасы Тәтеш өязе җирләре – тарихи яктан мөһим урыннар. Төбәк халкының бирeдә урнашуы да төрле этапларда барган, шуңа тарихи истәлекләр дә күптөрле һәм төрле тарихи чорларга карый. Тәтеш өязе җирләренең зур өлеше Идел буе Болгар дәүләте составына кергән һәм бу урыннар дәүләтнең мөһим икътисади төбәге булып саналган. Дәүләт оешканчыга кадәр үк тә бу җирләрдә төркиләрнең эзләре булуы мәгълүм.

***Нумизматик истәлекләр.*** Тәтеш төбәге үзенең нумизматик истәлекләре белән бай, чөнки хәзерге Олы һәм Кече Әтрәч авыллары урыннарын-

да Идел буе Болгар дәүләтенең акча сугу үзәге була. Монда табылган акчалар коллекциясе «Әтрәч хәзинәсе» дигән исем белән билгеле. Шундый 4 хәзинә табыла. Көмеш тәңкәләр хәзинәсе турында 1891 елда А.Ф. Лихачев тарафыннан хәбәр ителә. Ул үз хезмәтендә 13 см зурлыгындагы, хәзерге үлчәү берәмлеге белән 203,7 г (47 ¾ золотник) авырлыгындагы, көмеш коелмасының рәсемен үз мәкаләсендә бирә. Авыл кешеләре әлеге хәзинәне читтән килгән бер сәүдәгәргә 700 сумга сатып җибәрәләр. 1856 елда табылган хәзинәдә XIII–XIV йөз ахырына караган 10000 нән артык көмеш тәңкәләр булган, 1282–1393 елларга караган 2297 тәңкә тасвирланган. Бу хакта рус археологы, шәрык белгече, нумизмат П.С. Савельев мәгълүмат бирә. 1932 елда Кече Әтрәч авылында 200 г бакыр тәңкә акчалар табылган, бу хәзинә турында Д.М. Мөхәммәтшин мәкаләсендә генә искә алына [6], кызганычка каршы, бу истәлекләр махсус тикшерелмәгән. Әхмәт Булатов, А.Х. Халиков язмаларында бу вакытта табылган бакыр акчаларның авырлыгы 5 кг авырлыкта дип күрсәтелә [9]. 1954 елда табылган хәзинә зурлыгы ягыннан иң зурысы, монда Токта хан чорыннан башлап Бик-Булат чорына кадәрге (710–793 еллар – һиҗри ел исәбе буенча, милади ел исәбе буенча якынча 1332–1415 еллар) 20 мең Җүчи чоры көмеш тәңкәләре бар. Бу хәзинә тарихчы галим Әзһәр Мөхәммәдиев тарафыннан тәфсилләп тикшерелгән [7].

Олы Әтрәч тирәлегеннән табылган тәңкәләр турында 2003 елда С.В. Гумаюнов, И.В. Евстратов тарафыннан мәкалә язылды, анда 42 көмеш тәңкә, 144 бакыр акча турында сүз бара [4]. Бу акчаларның иң борынгысы XIV йөз башы белән билгеләнсә, иң соңгылары 1371–1372 (773 ел һиҗри ел исәбе белән) елгы тәңкә һәм 1383–1384 (785 ел) елларга карый торган дөя рәсеме төшерелгән пул. «Әтрәч хәзинәсе»нең тулы тасвирламасы белән нумизматика белгечләре хезмәтләрендә танышырга мөмкин [8]. Кызганычка каршы, бу хәзинәдәге барлык акчалар да нумизматлар тарафыннан әлегә кадәр өйрәнелеп бетерелмәгән.

«Әтрәч хәзинәсе» турында сүз алып барганда халык 1954 елгы табышны хәтердә тотып сөйли, аның табылу тарихы да телдән-телгә риваять рәвешендә бәян ителә. Бу җирлек элек-электән тарихи урын икәне билгеле булса да, фән әлеге хәзинә турында шактый соңлап кына белә. Авыл халкы җир эшләре вакытында берәм-сәрәм чыккан тәңкәләрне җыя торган булган, вак акча җыю балалар өчен дә кызыклы шөгыль. Яңгырдан соң тәңкәләр Зур Әтрәчнең «Тәңкә сызасы» дип аталган кырында юылып җир өстенә чыга торган була, халык аларны җыеп күкрәкчәләр ясаган, калфакларын бизәгән, чулпылар ясаганда кулланганнар. Халык «Изгеләр өсте» дип аталган кырда хәтта алтын тәңкәләр дә табылуын хәтерли. Авылның абыйлы-энеле Хәйруллиннар кыр эшләреннән кайтканда энесе ялтырап торган металлга игътибар итә, әмма абыйсы аңа «Ташла, ул зәхмәтле нәрсә», дип алырга рөхсәт итми. Халык сөйләве буенча, соңыннан, энесеннән качып кына килеп, пул алтын акчаны үзе ала, шуннан кисәк кенә баеп китә.

Басу сукалаганда трактор төрәне чүлмәк авызын ваткач чәчелгән акчаларга колхоз малларын көтүче Садыйков Рәмис тап була. Алар хәзинәне Мансур Гәрәев белән бергәләп җыеп алалар. Берсе 10 кг га якын, ә икенчесе 1 кг да 600 г тәңкә җыя. Хәзинәнең зур өлеше тирә-күршеләргә, дусларга тарала; әлбәттә, борынгы акчалар башкаларда да зур кызыксыну уята. Калган өлешен Р. Садыйков – 8 кг 200 г , М.Гәрәев – 1 кг 600 г акчаны Апас районы милиция бүлегенә илтеп тапшыралар. Бу табыш хакында ишеткән башка авылдашлар да хәзинә урынына килеп, беркүпмедер хәзинә иясе булалар. Алар да табылган борынгы акчаларны дәүләткә тапшыралар. Шулай да, бу авыл кешеләрендә кайбер борынгы тәңкәләр саклана. Билгеле, авыл кешесе бер өлеш табышын яшереп булса да үзендә калдырган. Көмеш, бакыр акчалардан гыйбарәт булган әлеге коллекция Татарстан Республикасы Милли музей фондында саклана. Бу хәзинә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалыннан А.Х. Халиков аша 1957 елның 29 апрель датасы белән 1145 номерлы акт нигезендә музейга тапшырыла. Аңа № КПНу-33843 инвентарь номеры бирелә. Хәзинәне тапкан Р. Садыков һәм М. Гәрәевләр 1000 сум күләмендә акчалата бүләккә ия булалар. Шул ук Кече Әтрәч кырыннан 88 көмеш тәңкә табыла, аларны 1965 елның 7 июлендә 3642 номерлы акт белән шулай ук музей фондларына тапшырылалар. 97,6 г авырлыктагы хәзинәне тапшыручы – А.С. Җамалетдинов [11, б. 20].

1954 елгы табыш билгеле булганнан соң, бу урынны археолог А.Х. Халиков һәм нумизмат Ә. Булатов килеп тикшерә. Акчалар арасында XIV гасырга караган 20 алтын акча булуы да мәгълүм, алар Һиндстан патшасы Потан идарә иткән чорныкы, димәк, бу, үз чиратында, әлеге җирлекнең сәүдә даирәсе хакында сөйли. Болгар дәүләтенең мөһим бер өлеше булган Тәтеш җирләре, Иделнең уңъяк яры Булат Тимер явы вакытында таланган [11, с.70–72]. Шул вакыйгалар белән бәйле рәвештә Болгар дәүләтенең Шонгаты шәһәрлегендәге (хәзерге Әтрәч авылы җирлекләре) акча сугу үзәге дә җимерелә. Кече Әтрәч кырында табылган акчалар билгеле бер авырлык нормаларына туры китереп сугылган. Алар Урта Идел сәүдәсендә әйләнештә йөргәннәр, аларның күпләп табылуы да шул хакта сөйли. Халыктан җыеп алынган 1597 тәңкәнең 1376-сы нумизматлар тарафыннан өйрәнелгән. Бу акчалар барысы да Идел буенда Алтын Урда чорында сугылган акчалар. Вакыты ягыннан караганда табылган акчалар 100 ел эчендә 20 хан исеменнән сугылган. Галимнәр билгеләве буенча, иң борынгы акча 1310 елда Токта хан исеменнән Сарай шәһәрендә, ә иң соңгысы, 1410 елга караганы Булат хан исеменнән сугылган. Хәзинәдәге иң зур коллекцияне Җанибәк хан идарә иткән чор акчалары тәшкил итә. 1376 акчадан 17-се Тукта ханныкы, 204-е – Үзбәк ханныкы, 650-се – Җанибәк ханныкы, 199-ы – Бирдебәк ханныкы; 6-сы – Көлнә хан, 82-се – Хызыр хан, 22-се – Туктамыш хан исеменнән чыккан. Коллекциядәге акчаларның күп өлеше (348 тәңкә) Мөрид хан исеменнән Гөлстанда сугылган. Тарихта билгеле булган Гөлстан-махруса һәм Гөлстан әл-

җәдиднең берсе нәкъ менә Шонгаты – Тәтеш өязе Әтрәч авылы тирәсендә булган.

Әтрәч җирлегендә табылган акчалар арасында Яңа Сарайда 384 данә, Гөлстанда – 460, Азак (Азов) шәһәрендә – 81 данә, шулай ук Болгар шәһәрендә, Хорезмда (Хива), Маҗар шәһәрендә (Төньяк Кавказ, Кума елгасы буенда), Мокшыда (Пенза өлкәсе Норавча районында), Ордуда (Казан белән Сарытау арасында) сугылган акчалар бар.

Әтрәч җирлегеннән бары тик 24 чакрым ераклыктагы Каратун авылы янында да хәзинә табыла. 1986 елның 26 маенда хәзерге Апас районына карый торган Каратун янында юл ремонтлау эшләре вакытында бульдозерга эләгеп ватылган бакыр казаннан Җүчи Олысы чорына караган тәңкәләр коела. Бу хәзинә 24200 тәңкәдән гыйбарәт, зур күпчелеге Җүчи чорына караган көмеш дирхәмнәр, араларында бары тик 4-се генә бакыр акча булган. Бу – Җүчи Олысы чорына караган иң зур, күләмле хәзинә санала. Моннан кала, тәңкәләр югары сыйфатлы көмештән коелуын, аларның составында көмеш составы хәтта 90 % ка җитүен әйтеп китү кирәк. Бу хәзинә, составында Алтын Урда чорында хакимлек иткән барлык ханнарның да тәңкәләре булу белән уникаль. Гомүмән, Тау ягы нумизматик материаллар белән гаять бай як. Шулай да, археолог Р.Г. Фәхретдинов фикеренчә, Каратун хәзинәсе барыннан да өстен тора [10, б. 9]. Бу хәзинәне өйрәнүче Г.А. Федоров-Давыдов эшен дәвам итеп, тәңкәләрне тасвирлаган Җ.Г. Мөхәммәтшин Каратун хәзинәсе «урта гасыр тарихы өчен генә түгел, ә барлык Алтын Урда нумизматикасы өчен зур әһәмияткә ия» дип белдерә [10, б. 9].

Каратун хәзинәсеннән соң бер ел үткәч, Апас районына карый торган Борындык авылы янында Мәңге һәм Арык-Буга исеменнән Болгар шәһәрендә сугылган 906 көмеш тәңкә табыла. Хәзинәгә мәктәп укучылары урман янында юлыгалар, әлбәттә кызыксынучан җирле халык арасында аларның бер өлеше таралып бетә. Кызганыч, беркүпмедер өлеше фән өчен югалган. Бу – XIII гасырга караган иң мөһим хәзинәләрдән санала, алар кызыл балчыктан яндырып эшләнгән савытка тутырып 1260 нчы елларда күмелгән тәңкәләр. Г.А. Федоров-Давыдов Болгарда сугылган әлеге тәңкәләр нигезендә, Болгар шәһәре Алтын Урданың тәңкә суккан иң беренче шәһәре, дигән фикер белдерә. Моннан кала, бу – Болгар һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге булуын да аңлата торган билге.

XIX гасыр ахырында Е.Т. Соловьев тарафыннан Сөйкидә (хәзерге Кама Тамагы районы) Алтын Урда чорына караган тәңкәләр, шул исәптән Хызыр хан исеменнән сугылган акчалар да, табыла [9, с.59], Тәтеш районына карый торган Урюм авылының да тәңкә хәзинәсе билгеле.

***Кабердашлар.*** Тау ягында сакланып калган тарихи кабердашлар шактый, борынгы зиратлар да аз түгел, чөнки бу җирләрдә халык шактый тыгыз яшәгән һәм таза тормыш алып барган. Матди мөмкинлеге булган кеше зур, бизәкле һәм зәвыкле кабердашлары куя алган. Кызганычка каршы, хәзерге вакытта ташлары авып, яисә таланып беткән борынгы зи-

рат урыннарының инде күбесе билгесез. Әмма җирле халык телендә сакланган риваятьләр, тарихи язмалар, археологик казу эшләре нәтиҗәләре аша аларның булганлыгын һәм якынча урыннарын ачыклау мөмкинлеге бар.

Сөйки белән Мукшә Каратае (хәзерге Кама Тамагы районы) арасында «татар зираты» дигән Болгар чорыннан ук килгән бик зур зират булган. Казан ханлыгы чорында да бирегә җирләгәннәр. Шулай ук, Салтыган авылы каберлегендә өч тарихи таш сакланып калган, шуларның икесе 1309 һәм 1325 елларга карый. Болгар чоры каберлекләре Шәмбалыкчы авылында да булган, алар 1961 елда Һ. Йосыпов тарафыннан өйрәнелгән, Кече Бола елгасы буендагы Байтирәк авылындагы болгар каберлекләренә Ш.Мәрҗани дә игътибар итә, аннары бу җирлек Н.И. Золотницкий, Һ.Йосыпов тарафыннан тикшерелгән. Ш.Мәрҗани Байтирәк исемле чуаш авылы янында да борынгы таш булуы хакында: «Ул авылның чиркәве янында түбән ягы сынып төшкән таш бар – озынлыгы биш чирек кадәр, ә киңлеге бер аршыннан бер илле ярымга кимрәк. Ул ташның икенче кисәге икенче бер урында ята. Болгар ташларындагы кебек, куфи һәм нәсех язулары аралаштырып язылган». Аның текстын да бирә: «Әл-хөкме лилләһил-галиил-кәбир. Юныс улы Хаҗи бәлүке (билгеле) рәхмәтулләһи галәйһи рәхмәтән васигатән, вафат бәлкәви тарих җият җүр җирем җити җал сәвер аех җирем биш көн ите» [5, б.75].

Ш.Мәрҗани Олы Яльчек исемле чуаш авылының басуында да каберлек барлыгын яза. Шулай ук бер таш куфи һәм нәсех язулары белән аралаштырып, чокып язылган, аның тексты: «Һуәл-хәййе әлләзи ля ямүт. Салавыш углы Муса углы Бәйрәм Хаҗи углы Биккенә» [5, б.75], дип укыла.

Колгана, Кошта, Олы Фролово, Олы Шәмәк, Бәки, Олы Кариле һәм Кече Кариле, Салтыган, Ишим (Кама Тамагы районы) авыллары зиратларында да Болгар чоры кабертáшлары булган. Алар 1940–1960 елларында СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы оештырган экспедицияләр вакытында тикшерелгәннәр [9, с.167–188].

Тәтеш өязенә кергән Пролей-Каша авылы зираты тарихчы Г. Әхмәрев тарафыннан 1910 елда өйрәнелә [1]. Моннан кала, галим фикеренчә, Урюм авылы (Тәтеш районы) янында Болгар чорына карый торган зур зират булган. Ул бу урынны караганда зиратның хәле инде шактый начар хәлдә, сөрү җиренә әйләнгән. Сынган, ватылган ташлар бер өемгә өеп куелган була. Шулар арасыннан, галим кисәкләрне җыеп, куфи язуындагы бары берничә сүзне укый ала. Бу зират турында Х.Фәезханов, И.А. Износков, Е.Т. Соловьев хезмәтләрендә искә алына [9].

Г.Әхмәрев татар җәмәгатьчелегенә борынгы зиратларга игътибарны арттыру зарурлыгын ассызыклый: «Тәтеш өязенең Карабай карьясе белән Сәүтек карьясе (авылы – *Э.С.*) арасында бер зур иске зират бар, кабер өстендә уеп-уеп куелган ташлары да бик күп, ләкин язулысы юк, бу зират соңрак заманда гына ташланган булса кирәк, каберләрнең каю тарафка таба каратып казылганы да беленеп тора. Ислам зираты икәне бик

мәгълүм – кабер өсләре күбесенчә чокырланыбрак тора, ихатасы юк, уртасыннан юл йөри, шул кабер өсләреннән үтеп бәгъзе (кайбер. – *Э.С.*) каберләрнең чокырына арба көпчәкләре төшеп-төшеп китә, кабер әйләнәсендә уеп куелган ташлар өстеннән менеп уза» [2]. XX йөз башында ук шундый хәлдә булган зиратның хәзерге вакытта эзе дә калмаганлыгы инде аңлашыла. «Шул ике авылның мөселманнары шулкадәр илтифатсыз: ата-бабаларының мөкаддәс зиратларын шул дәрәҗәдә тоталар. Ике авылга дүрт мулласы бар, дүртесе дә картлар, бу юлны аз гына читтәнрәк җибәрергә, әлбәттә, бик мөмкин, ихата тотып куярга хәлләре булмаса, канау казып әйләндерергә мөмкин, моңар акча чыкмый, халык бушрак вакытта бөтен авыл кешесе чыгып, бер көндә казып, әйләндерәчәкләр, имамнар тарафыннан илтифат кына кирәк» [3, б. 182–185]. XX йөз башында, дини атрибутларга сак караган чорда ук, тарихи истәлекләргә карата булган игътибарсызлык мирасның югалуына китерә.

Г.Әхмәрев Җанбакты авылының чиркәү ишеге төбенә түшәлгән ике язулы ташка тап була. Шуның берсенең язуын күчереп тә ала, ул аны «665 ел мөкаддәм (элек – *Э.С.*) язылган», дип вакытын билгели. Галимгә Каратун авылында очраган гарәп язулы таш та, аның фикеренчә, борынгы Болгар җирлеге – Әтрәч зиратыннан китерелгән булса кирәк [3, б.182–185].

Г.Әхмәрев Тәтеш шәһәрендә дә чиркәү салганда бер зират ташы табылуы хакында яза. Бу таш Тәтеш җирлегенең үзенеке булганмы, яисә чиркәү нигезенә түшәү өчен башка урыннан китерелгәнме – билгесез. Бу ташны күргән Гайнетдин Әхмәрев «өстеннән арба юлы йөреп, бу таш урталай сынган, шул сәбәпле ахыргы өч сүзе таныrлык түгел. Бу сүзләрне калган берничә хәрефләрен карап кына шулай булырга кирәк дип, үзебезчә уйлап язып куйдык (алары бәлки безнеңчә дә түгелдер)». Тексты бу рәвешчә «Әл-хөкме Аллаһы әл-гали әл-кәбир Галәйе Аллаһы әүвәл гасый рәхмәтуллаһи галәйһи вә рәхмәтән васыйгатәнвафат ... тарихе җийат җур (әз һиҗрәти газыйм...)» [3, б. 182–185]. Г.Әхмәрев бу таш хакында Казан университеты каршында эшләүче Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә дә хәбәр итә, алар килеп тә карыйлар. Ташны полиция участогына китереп, койма буена язулы ягы белән өске якка таба каратып салганнар. Полиция участогында кадерсезләнгән бу ташны Археология, тарих һәм этнография җәмгыятеннән рөхсәт сорап, Тәтеш мәчетенең бер бүлмәсенә китереп кую хәстәре артыннан йөри, ә Тәтеш мулласы исеменә рөхсәт алуга да ирешә. Ташны күчерү галимнәргә киртә тудырмау шарты белән эшләнә. Г. Әхмәрев бу хәл турында: «Тәтешнең исправнигыннан сорадык: “Ул ташны алсак, сүз әйтүче булмасмы”, – дип. Исправник холыксыз нәрсә иде, язуымны укып карагач, тынычсызлана башлады: “Кайда ул, нинди таш”, – дип сорашып, безгә – “Губернатордан сораңыз”, – дип алырга рөхсәт ителмәде, үзе шул көндә үк мәзкүр ташны полицийскийларны кушып, эзләтеп алдырган да, полициягә китереп, бер утын амбарына куйдырган, хәзердә кайдадыр, мәгълүм түгел. Шул 600 еллар

мөкаддәм (элек. – *Э.С.*) (хатты куфи белән) аяте Кәримә язылган ташны хәзердә эзләнеп алынса, яхшы булыр иде» [3, б. 185].

Идел алды регионында Болгар тарихының соңгы чорына караган археологик истәлекләр тупланган үзәк – Үләмә һәм Коры Үләмә елгалары бассейны. Галимнәр шушы регионда 50 ләп Алтын Урда истәлекләре булу хакында әйтәләр. Шундыйлардан, алар билгеләвенчә, аерым игътибарга лаеклысы – Олы Әтрәч авылы зираты. Әтрәч авылы җирлеге, шул исәптән аның борынгы зираты, 1884 елда Е.Т. Соловьев, 1943 елда Ә.Булатов, 1949 елда Н.Ф. Калинин, 1961 елда Һ.Йосыпов, 1970 елда СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы экспедицияләре тикшерә [9, с.180]. Борынгы каберлекләр Олы Әтрәч авылыннан көнчыгышка 0,3 чакрым ераклыкта урнашкан, 7600 кв. м территорияне биләгән. Борынгы Болгар заманы зиратлары күп булса да, сакланып калганнары арасында бу зират территориясе ягыннан иң зурысы һәм иң үзенчәлеклесе. Әхмәд Булатов фикеренчә, бу зиратта 1000 гә якын кеше җирләнгән булырга тиеш.

Борынгы Шонгаты җирләре булган урыннар – Әтрәч авылы янындагы борынгы каберлекләр халыкта изге урын буларак кабул ителгән. Халык аны шулай «Изгеләр зираты» дип атап та йөрткән. Халык дога кылу өчен дә, яисә кайгы-хәсрәтләре булганда да, авырулардан сихәтләнү өмете белән дә бу урыннарга килә торган булган. Тәтеш шәһәренә укытучы итеп билгеләнгән Г. Әхмәрев бу төбәктә эшләгән елларында (1891–1903) Тау ягындагы каберлекләрне, борынгы тарихи урыннарны өйрәнә. Аның төбәк тарихы белән профессиональ кызыксынуы нәкъ менә шушы елларда башлана. Халык белән аралаша, аларның хатирәләрендә булганнарны язып ала, Әтрәч халкы аңа ике Әтрәч авылының (Зур һәм Кече Әтрәч авыллары) кешеләре Болгар шәһәре Шонгатыдан күчеп утыручыларның нәсел дәвамчылары булуларын сөйлиләр. Бу шәһәрнең халкы болгарлар белән (ягъни пайтәхетләре булган Болгар шәһәренең мөселманнары белән) кыз алышып, кыз бирешеп йөргәннәр. Шунда шәһре Болгарга йөргән туры юлларын да күрсәтәләр. Зиратлары янында күп болгар әйберләре табыла, хосусан, «әзгәри» дип атала торган болгар тәңкәләре, элегрәк, Болгар заманында, акча урынына йөртелгән көмеш кисәкләре дә күп табылган, дип яза тарихчы. Гайнетдин Әхмәрев Әтрәч зиратындагы ташларга карап, һәм дә халык хәтерен дә исәпкә алып, биредә авыл түгел, ә Болгар шәһәре булган булырга тиеш, дип фараз итә. Аның фикеренчә, авыл кешеләре генә бу кадәр алты йөз елларга түзәрлек зур вә яхшы ташларны куя алмас иде. Шул ук вакытта ул авыл халкын тәнкыйть утына тота, мондый ташларга, зиратка авыл халкының мөнәсәбәте, битарафлыгы борчый аны.

XIII–XIV йөзләргә караган эпиграфик истәлекләрне саклаган Әтрәч авылы зираты XIX гасырда ук инде галимнәрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Иң беренчеләрдән булып Ш.Мәрҗани үзенең атаклы «Мөстафадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтенә Әтрәч зиратындагы кайбер

ташларның язмаларын урнаштыра. 1863 елда Мәрҗани бу авыл зиратында булып, монда Болгар чорына караган 21 кабер ташын барлый. XIX йөз башында аларның саны 50 ләп була. Ш.Мәрҗани билгеләвенчә, бу ташлар 1302, 1303, 1314, 1323, 1324, 1346 елларда вафат булган кешеләрнең каберләренә куелган. Халык сүзләре буенча, мондый ташлар биредә күп булган. «Моннан җитмеш еллар элек Әтрәчтән биш чакрым көньяктарак урнашкан Җанбакты исемле урыс авылы алпавыты шул авылга чиркәү салдырганда, нигезенә таш кирәк булгач, шундагы тигез ташларны кулай табып, мөселманнарның олылап хөрмәт иткән ташларыннан егерме-утызлабын агач чиркәүнең нигезенә куйдырган». Бу сүзләренә дәлил итеп шушы төбәк кеше сүзләрен китерә: «Әтрәч авылының сиксәнне узып барган мөәззине түбәндәге сүзләр сөйләде: “Мин бала чагымда атам белән шушы авылга йомыш белән барганда ул ташларны төзәтеп куйганнарын карап тордым”. Атам елап: “Менә, балам, безнең авылыбыздагы газизләрнең каберләре өстендәге ташларны чиркәү бусагасына куялар”, – дип әйтте» [5, б.76].

Бу авыл зиратына 1905 елда килгән Гайнетдин Әхмәрев 22 кабер ташы саный. 1949 елдагы тикшерүчеләр шулай ук 22 кабер ташын күрсәтә, ә инде Һ.Йосыпов өйрәнгәндә анда бары тик 16 кабер ташы була, ә хәзерге вакытта аларның саны бары тик 7 генә. Әтрәч авылының «Изге каберлеге»ндә үзәктәге җиде зират курган рәвешендә ясалган булган, әмма алар хәзерге вакытта җиргә иңеп беткән.

Саннарның шулай кимүенең сәбәбе төрле. Беренчедән, Ш.Мәрҗани тарафыннан сөйләнгән, кабер ташларын урыс авылларына алып китеп чиркәү төзелешендә, хуҗалыкта кулланылуы. Җирле халык ташларның Апас-Тәтеш юлына түшәлгәнен дә хәтерли. Бу хакта моның шаһиде булган Гайнетдин Әхмәрев тә ул язулы болгар кабер ташларын Җанбакты чиркәү нигезендә, Каратун авылында юлга түшәлгәнен яза. Икенчедән, җирле халыкның битараф мөнәсәбәте. 1906 елда «Азат» газетасында дөнья күргән «Иске зиратлар хакында» дигән мәкаләсендә әйтеп китә: «Һәр милләт – нәсараи булсын, яһүд булсын, хәтта мәҗүс таифәләре дә, ата-бабаларының зиратларын мөкаддәс санап, мөмкин кадәр тәрбияле тоталар, мондаен эшләр дине исламда хосусан мактаулы булса да, вилайәтебезнең мөселманнары иске зиратларын бик тәрбиясез, кызганыч хәлдә тоталар». Мисал итеп, башкалар белән бер рәттән иң беренче итеп Әтрәч авылы зиратын китерә: « ...шунда алты йөз еллар мөкаддәм куелган (20–25 кадәр) язулы ташлар да бар. Ихатасы юк, ташларның бәгъзеләре авып ята, бәгъзеләре сынгалап, берничә еллар мөкаддәм араларын сукалап, иген дә чәчкәннәр иде, шул сәбәпле бер баруыбызда бәгъзе ташларны күрер өчен иген арасыннан эзләп таптык, икенче мәртәбә баруыбызда такыр басу иде. Шул зират өстендә Әтрәч карьясенең сыер-сарык көтүе йөргәнен күрдек, бәгъзе хайваннар ташлар арасына ятканнар, бәгъзеләре ташка ышкылып

торалар. Хайван йөргән сәбәпле, зират өстендә тирес тә күрелде. Шунда бер көтүчедән сорадык: “Ник болай хайван йөртеп, зиратны кадерсез итәсез? – дип. Йөртәбез шул инде, йөртмә дип әйтүче дә юк”, – дип җавап бирде. Дәхи зыярат кылырга килүчеләр хакында сораштык. “Килүчеләр була, кичә дә бер пар ат белән килеп, Коръән укып киттеләр, ләкин белеп булмый, әллә кеше, әллә фәрештәләр булды – Ходай белсен. Мин сезне дә танымыймын, миңа сез дә әллә кем”, – диде. Бу ташлар элегрәк бик күп булган имеш, ләкин мөселманнарның илтифатсызлыгыннан күбесен якындагы урыслар урлап ташыган, диләр.... Мондаен әсәрләрне мәгърифәтле милләтләр бик саклыйлар, безгә дә сакласак, бәлки киләчәк заманда бераз файда булыр иде» [3, б. 185].

Җанбакты авылындагы Әтрәч ташының һәм дә Әтрәч зиратындагы тагын бер ташның күчермәсен ул үзенең атаклы «Болгар тарихы» дигән хезмәтенә кертә [3, б.70–74].

Чистай өязендәге Змеево авылы чиркәве нигезендә яткан 1306–1307 елларга карый торган таш язмасында да Әтрәч авылы белән бәйлелек бар, бу таш Әтрәч бабайның кызы Әлкискә куелган. Хәзерге вакытта бу таш Мәскәүдә ГИМның экспозиция залында саклана.

Ш. Мәрҗани 21 таш булуы хакында язган, әмма 1943 елга бары тик 14 ташның гына язуы укырлык дәрәҗәдә була, яңгыр, кар астында торган таш истәлекләр инде үз сыйфатын ел саен җуя баралар. Укырлык булган 14 таш барысы да куфи язуы белән язылган, әмма, галимнәр билгеләвенчә, аларның күбесе каберташ ясау осталары тарафыннан эшләнмәгән дигән фикер әйтелә. Тел ягыннан килгәндә бу каберташ язмаларының теле фәндә «икенче стиль»гә – «чуашизм элементлары» белән язылганга туры килә. XIV гасырның беренче яртысына караган бу ташларның теле – хәзерге татар теленең борынгы Болгар чорындагы кулланышы, биредә чуаш элементлары булу – ул ташъязмаларның хәзерге чуаш теленә мөнәсәбәте хакында сөйләми, алар арасында аермалар зур. Бу тел – әлеге чорда шушы җирлектә кулланылган тел. Әлбәттә, тел һәрвакыт үсештә, үзгәрештә һәм камилләшүдә.

1964–1971 елларда Әтрәч авылында каберлек өсте ачыла, аларның берсе ир кешенеке, ә икенчесе хатын-кыз каберлеге була. Моны күргән картлар сөйләве буенча, суган кабыгына төреп мумияләштерелгән кабер ияләре яхшы сакланган. Аларның чәчләре аксыл, кул чуклары тездән түбән булуга игътибар итәләр. Бу – шул чорда яшәгән җирле халыкка хас булган кыяфәт.

Әтрәчнең «Изге зираты» галимнәр тарафыннан соңгы елларда да тикшерелде, әмма ул территориясе ягыннан элекке чор белән чагыштырганда бик нык кечерәйгән. Күп җирләре басу составына кереп киткән. XIX гасырда ук бу җирләр керәшеннәргә бирелгән, аны сөрү җире иткәннәр дип сөйлиләр. 9 гектар җир биләгән зиратның сакланып калган өлеше

хәзерге вакытта бары тик 0,93 гектар зурлыгында гына. Күренекле драматург Туфан Миңнуллин, аның энесе Альберт Миңнуллин ярдәме һәм Мөнир Вәлиев җитәкчелегендә Әтрәч халкы ясаган өмә белән бу зират тәртипкә китерелде, сакланып калган ташлар төзәтелеп, зират тимер койма белән әйләндереп алынды. «Шонгаты» оешмасының активистлары, тарих өчен, тарихи һәйкәлләрнең язмышы өчен янып торган кешеләр тырышлыгы белән ел саен бу каберлекләрдә ятучы ата-бабалар рухына дога укыла, корбан чалына. Галимнәрне, тарих белән кызыксынучыларны, җәмәгать эшлеклеләрен җыеп «Әтрәч укулары» дигән халык җыенын җыеп фәнни чыгышлар тыңлана.

Тәтеш төбәге Идел буе тарихының мөһим тарихи җирләре булуы, югарыда аталган чыганаклардан кала, археологик истәлекләр белән дә раслана. Кызганычка каршы, Идел буе Болгар дәүләте тарихын өйрәнгәндә Иделнең уңъяк яры хакындагы мәгълүматка тиешле игътибар бирелми. Шунлыктан, Идел буендагы Болгар дәүләте берьяклы, тулы булмаган хәлдә тәкъдим ителә. Әлеге тикшерү хезмәте бу бушлыкны тутыру, бу хилафлыкны бетерү юлында бер адым буларак үз бурычын үтәргә тиеш.

**Чыганаклар һәм әдәбият**

1. *Ахмаров Г.* Отчет о поездке с археологической целью летом 1909 года в Свияжский и Тетюшский уезды Казанской губернии // ИОАИЭ. 1910. Т.XXVI. Вып.4. С.398–408.

2. *Әхмәрев Г.* Иске зиратлар хакында // Азат. 1906. 30 март.

3. Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык. Казан: Хәтер, 2000. 384 б.

4. *Гумаюнов С.В., Евстратов И.В.* Шонгат – неизвестный монетный двор Золотой Орды // Одиннадцатая Всероссийская нумизматическая конференция. Тез. док. и сообщ. СПб.: Гос. Эрмитаж, 2003. С.79–81.

5. *Мәрҗани Ш.* Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан: Татар. кит. нәшрияты, 1989. 414 б.

6. *Мухаметшин Д.Г.* Клады Тетюшской округи // Исследования по средневековой археологии Евразии. Казань: Школа, 2012. С.197–217.

7. *Мухаммадиев А.Г.* Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М.: Наука, 1983. 168 с.

8. *Руденко К.А., Бугарчёв А.И.* Археологические и нумизматические находки из окрестностей села Большие Атряси (Тетюшский район РТ) // Поволжская археология. 2015. №3 (13). С.156–175.

9. *Фахрутдинов Р.Г.* Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. 217 с.

10. *Федоров-Давыдов Г.А., Мухаметшин Д.Г.* Каратунский клад джучидских монет XIV века. Том 1. Казань: Изд-во Казан. ун-та «Палеограф», 2018. 386 с.

11. *Халиков А.Х.* Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария. Казань: Фэн, 1994. 168 с.

## Нумизматические и эпиграфические памятники Тетюшского края

***Э.К. Салахова***
*Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ*
*Казань, Российская Федерация*

Тетюшский уезд, который включал в свой состав территории современных Тетюшского, Апастовского, Камско-Устьинских районов и часть Буинского района Республики Татарстан, являлся примечательным регионом Поволжья. В данном исследовании рассматриваются исторические памятники, сохранившиеся на этой земле, а для обозначения территориальных границ изучения автор употребляет термин «Тетюшский край». Эта земля являлась частью Волжской Булгарии, а также она оставалась важным центром государства тюрко-татар и в период Джучиева Улуса. К сожалению, долгое время изучение исторических памятников тюрко-татар ограничивалось лишь территорией современного города Болгар и его окрестностей. Исторические артефакты, созданные в правобережной части государства, незаслуженно оставались в тени.

Цель данного исследования – через нумизматические материалы и эпиграфические памятники осветить историю Тетюшского края, подчеркнуть его значимость в истории Волжской Булгарии и Джучиева Улуса. Актуальность исследования в данном направлении не вызывает сомнения, так как комплексное изучение исторического материала дает возможность детально изучить историю не только этого региона, но и восполнить малоизвестные страницы истории татарского народа.

В статье основное внимание направлено на рассмотрение богатого нумизматического материала. На территории Тетюшского, Апастовского районов были найдены исторически важные сокровища монет, которые в науке получили название «Каратунский клад» и «Атрясовский клад». Также и в других деревнях Тетюшского края были обнаружены серебряные дирхемы. Исследователями установлено, что монетный двор Волжской Булгарии располагался вблизи булгарского города Шонгуты (ныне территория Тетюшского района). Во второй части статьи автор делает попытку определить комплекс эпиграфических памятников времени Волжской Булгарии и Джучиева Улуса на территории бывшего Тетюшского уезда и обозначить места древних кладбищ предков татар.

*Ключевые слова:* нумизматика, эпиграфические памятники, история Тетюшского края, история татарского народа, история Волжской Булгарии.

*Для цитирования:* Салахова Э.К. Тәтеш төбәгенең нумизматик һәм эпиграфик истәлекләре // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. 2022. Т.12, №3. С. 69–80.

# Numismatic and epigraphic monuments of the Tetyush region

***E.K. Salakhova***
*Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*

Tetyushsk district, which included the territories of modern Tetyushsk, Apastovsk, Kamsko-Ustinsk districts and part of the Buinsk district of the Republic of Tatarstan, was a remarkable region of the Volga region. This study examines historical monuments created on this land, and to designate the territorial boundaries of the study, the author uses the term "Tetyushsk region". This land was part of Volga Bulgaria, and it also remained an important center of the Turkic-Tatar state during the period of the Juchi Ulus. Unfortunately, for a long time the study of historical monuments of the Turkic-Tatars was limited only to the territory of the modern city of Bulgar and its environs. Historical artifacts created in the right-bank part of the state undeservedly remained in the shadows.

The purpose of this study is to expand and deepen the diverse history of the Tetyushsk region through numismatic materials and epigraphic monuments, to emphasize its importance in the history of Volga Bulgaria and Juchi Ulus. The relevance of the research in this direction is beyond doubt, since a comprehensive study of historical material makes it possible to study in detail the history of not only this region, but also to fill in generally little-known pages of the history of the Tatar people.

The article focuses on the consideration of a rich numismatic material. Historically important treasures of coins were found on the territory of the Tetyushsk and Apastovsk districts, which were named in science as the "Karatunsk treasure" and "Atryasovsk treasure". Silver dirhams were also found in other villages of the Tetyushsk region. Researchers have found that the mint of Volga Bulgaria was located near the Bulgarian city of Shonguta (now the territory of the Tetyushsk district). In the second part of the article, the author defines a complex of epigraphic monuments of the time of Volga Bulgaria and Juchi Ulus on the territory of the former Tetyushsk district, also indicates the places of ancient cemeteries of the ancestors of the Tatars.

*Keywords*: numismatics, epigraphic monuments, history of the Tetyushsk region, history of the Tatars, history of Volga Bulgaria.

*For citation:* Salakhova E.K. Numismatic and epigraphic monuments of the Tetyush region. From History and Culture of Peoples of the Middle Volga Region. 2022, vol. 12, no. 3, pp. 69–80. (In Tatar)

**Информация об авторе:**

**Салахова Эльмира Кадимовна** – кандидат исторических наук, старший научный сотрудник отдела новой истории Института истории им. Ш.Марджани АН РТ (Казань, Российская Федерация); e-mail: ilsalah@mail.ru

**Сәлахова Эльмира Кадим кызы** – тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының яңа тарих бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре (Казань шәһәре, Россия Федерациясе).

**Salakhova Elmira Kadymovna** – Cand. Sci. (history), Senior Researcher of the Department of Modern History, Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (Kazan, Russian Federation).